КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 декабрь г.Казань № 1239

2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында

Россия Федерациясе гражданнарының түләүсез медицина ярдәме күрсәтүгә конституциячел хокукларын тәэмин итү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре программасы турында» 2020 елның 28 декабрендәге 2299 номерлы карарын үтәү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын (алга таба - Программа) расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2021 елда Программа кысаларында күрсәтелгән медицина хезмәтләре өчен исәп-хисапларның тәмамлануы 2022 елның 15 февраленә кадәр гамәлгә ашырыла;

Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы медицина оешмалары тарафыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә законнар нигезендә билгеләнгән тәртипләр һәм формалар буенча мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә эшчәнлек турында хисаплылык һәм Программа расланган көннән алып 14 көн эчендә – тиешле финанс елына финанс-хуҗалык эшчәнлеге планы тапшырыла;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы буенча медицина ярдәме өчен түләү турында Тариф килешүе төзү;

медицина оешмалары тарафыннан күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күрсәтелә торган медицина ярдәме өчен түләүнең вәкаләтле органына тарифлар һәм түләү тәртибен әзерләүгә һәм раслауга тәкъдим итү;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Программаны һәм медицина ярдәме өчен түләүгә билгеләнгән тарифларны рәсми сайтта урнаштыру;

медицина оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлегенең килештерелгән планнарын «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә 2021 елның 15 февраленә кадәр тапшыруны тәэмин итү.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондына «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2020 елның 27 ноябрендәге 78-ТРЗ номерлы һәм «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 2020 елның 27 ноябрендәге 79-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарында күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Программаны гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итүне гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин